Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге
Мерәс авылы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«20» ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Мерәс авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Мерәс авылы Сәйдәш урамнарындагы ясалма юл тигезсезлекләрен урнаштыру буенча эшләр башкару;

-Мерәс авылы Гыймадиев урамы юлларын ремонтлау.

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина